МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.06.2022 г. Казань № 1616

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы даруларны күпләп сату оешмаларыннан һәм даруханә оешмаларыннан тыш, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган I–III исемлеккә кертелгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше эшчәнлеген тормышка ашырганда лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрә торган бәяләү кәгазе формасын раслау турында

2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның $19^1$ статьясындагы 8 өлеше, Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләр культивациясе буенча эшчәнлекне лицензияләү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 декабрендәге 1085 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 3 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы даруларны күпләп сату оешмаларыннан һәм даруханә оешмаларыннан тыш, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган I–III исемлеккә кертелгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше эшчәнлеген тормышка ашырганда лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрә торган бәяләү кәгазе формасын расларга.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары В.В. Виниченкога йөкләргә.

Министр М.Н. Садыйков

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгы белән
расланды
_06.06.2022_№ _1616__

Форма

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның, федераль башкарма хакимият органнары карамагындагы даруларны күпләп сату оешмаларыннан һәм даруханә оешмаларыннан тыш, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган I–III исемлеккә кертелгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше эшчәнлеген тормышка ашырганда лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрә торган бәяләү кәгазе**

1. Лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү формасы, теркәлү номеры һәм лицензия бирү турында гаризаны теркәү датасы (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

2. Юридик затның тулы яки кыскартылган исеме (булган очракта) һәм оештыру-хокукый формасы, аның урнашу урыны адресы, юридик затның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

3. Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адресы (адреслары):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

4. Лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрү урыны (урыннары):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрү турында карар реквизитлары:
______________________________________________________________________________

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүче һәм бәяләү битен тутыручы вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса):
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

7. Лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның лицензия таләпләренә туры килү (туры килмәү) турында танычларга тиешле контроль сораулар исемлеге:

| № т/п | Лицензия таләпләре эчтәлеген чагылдыра торган контроль сораулар исемлеге | Структур берәмлекләрен күрсәтеп, мәҗбүри таләпләр билгеләнгән норматив хокукый актлар реквизитлары | Лицензия таләпләренә туры килү (туры килмәү) турында сорауларга җавап | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | килешмәү | |
| 1 | Лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) гариза биргән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) үтәү өчен милек хокукы яки башка законлы нигездә үзенеке булырга тиешле кирәкле урыннары бармы? | Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләр культивациясе буенча эшчәнлекне лицензияләү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 декабрендәге 1085 номерлы карары белән расланган Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләр культивациясе буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 4 пунктның «а» пунктчасы, 5 пунктның «а» пунктчасы | | | | |
| 2 | Россия Федерациясендә контрольдә тотылырга тиешле наркотик чаралар һәм психотроп матдәләрнең I–III исемлегенә кертелгән наркотик чаралар, психотроп матдәләр әйләнеше эшчәнлеген (алга таба – исемлек, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр) гамәлгә ашыру өчен лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) милек хокукы яки башка законлы нигездә үзенеке булырга тиешле кирәкле җиһазлары бармы? | Нигезләмәнең 4 пунктның «а» пунктчасы, 5 пунктның «а» пунктчасы | | | | |
| 3 | Медицина оешмасының – лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга | Нигезләмәнең 4 пунктның «а (1)» пунктчасы, 5 пунктның «а (1)» пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | лицензиясе бармы? | | | | | |
| 4 | Россия Федерациясенең наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында һәм оешманың һәм затларның наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше белән бәйле үзара йөкләмәләрне хезмәт шартнамәсенә кертү турында законнары белән әлеге затларны таныштыру өлешендә лицензия алырга теләүче (лицензиат) затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә кертү тәртибен үтиме? | Нигезләмәнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 5 пунктның «б» пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 6 августындагы 892 номерлы карары белән расланган Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә, шулай ук наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр прекурсорлары әйләнешенә бәйле эшчәнлеккә кертү кагыйдәләренең (алга таба – Кертү кагыйдәләре) 3 пункты | | | | |
| 5 | Хезмәт вазифалары буенча наркотик чаралар һәм психотроп матдәләрне алу мөмкинлеге булырга тиешле хезмәткәрләрнең уртача авырлыктагы җинаять, авыр һәм аеруча авыр җинаять яки наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә яки наркотиклы үсемлекләрне законсыз үстерүгә бәйле җинаять, шул исәптән Россия Федерациясеннән читтә кылынган җинаять өчен, түләнмәгән яки тәшерелмәгән хөкем ителүе турында эчке эшләр органнарының бәяләмәсе булу өлешендә лицензия алырга теләүче (лицензиат) затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә кертү тәртибен үтиме? | Нигезләмәнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 5 пунктның «б» пунктчасы; Кертү кагыйдәләренең 4 пункты | | | | |
| 6 | Җитәкченең наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә рөхсәт итүе турында карары булу өлешендә | Нигезләмәнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 5 пунктның «б» пунктчасы; Кертү кагыйдәләренең 2 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | лицензия алырга теләүче (лицензиат) затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә, шулай ук наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешенә бәйле эшчәнлеккә кертү тәртибен үтиме? | | | | | |
| 7 | Мәҗбүри психиатрия тикшерүе булу өлешендә лицензия алырга теләүче (лицензиат) затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә кертү тәртибен үтиме? | Нигезләмәнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 5 пунктның «б» пунктчасы; Кертү кагыйдәләренең 4 пункты | | | | |
| 8 | Хезмәт вазифалары буенча наркотик чаралар һәм психотроп матдәләрне алу мөмкинлеге булырга тиешле хезмәткәрләрнең наркомания, токсикомания, хроник алкоголизм белән авыруы булмавы турында дәүләт сәламәтлек саклау системасы яисә муниципаль сәламәтлек саклау системасы медицина оешмалары тарафыннан бирелгән белешмәләрнең булуы өлешендә лицензия алырга теләүче (лицензиат) затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә кертү тәртибен үтиме? | Нигезләмәнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 5 пунктның «б» пунктчасы; Кертү кагыйдәләренең 4 пункты | | | | |
| 9 | Эшчәнлек алып барыла торган объектларның һәм биналарның инженерлык-техник саклау чаралары белән җиһазланышына карата билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында наркотик һәм психотроп матдәләр әйләнеше буенча эшчәнлек алып барырга ниятләүче лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) | Нигезләмәнең 4 пунктның «в» пунктчасы, 5 пунктның «в» пунктчасы; 1998 елның 8 гыйнварындагы 3-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3 пунктының өченче абзацы «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» (алга таба – 3-ФЗ номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының бәяләмәсе бармы? | Федераль закон) | | | | |
| 10 | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешенә бәйле эшчәнлек алып барырга ниятләүче лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) җитәкчеләре составында тиешле һөнәри әзерлеккә ия булган белгече бармы? | Нигезләмәнең 4 пунктның «в» пунктчасы, 5 пунктның «в» пунктчасы; 3-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 11 | Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешенә бәйле эшчәнлек алып барырга ниятләүче лицензия алырга теләүченең (лицензиатның) штатында урта һөнәри, югары һөнәри, өстәмә һөнәри белем һәм (яки) наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше өлкәсендә башкарылучы эшләрнең таләпләренә һәм характерына туры килә торган махсус әзерлеккә ия хезмәткәрләр бармы? | Нигезләмәнең 4 пунктның «д» пунктчасы, 5 пунктның «ч» пунктчасы | | | | |

Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләр культивациясе буенча эшчәнлекне лицензияләү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 декабрендәге 1085 номерлы карары белән каралган лицензия таләпләренә лицензия алырга теләүченен/лицензиатның туры килүе/туры килмәве ачыкланды (кирәклесен ассызыкларга)

_______________________________________________ ________________________

(лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүче һәм бәяләү битен тутыручы вазыйфаи зат) (имза)

Бәяләү битен тутыру датасы «____»________________20_____ел

___________________________